**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_27__» ___10____ 2023 ел.** **№ __277___**

Азнакай муниципаль районы чикләрендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы халкының пассажирлар йөртү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итү максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законнар, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы чикләрендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документын әзерләү тәртибен, 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеш бүлеген гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документларын алып бару буенча җаваплы дип билгеләргә.

3. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы чикләрендә җирлекләр арасында гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру тәртибе турында» Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 18 декабрендәге 336 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 01.03.2024 елдан үз көченә керә дип билгеләргә

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары Р.Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
"_____" _______________2023 №___

**Гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документын әзерләү тәртибе**

**1.Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документын әзерләү һәм алып бару процедурасын (алга таба - планлаштыру документы) билгели.

1.2. Планлаштыру документы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан эшләнә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән раслана.

1.3. Планлаштыру документларында үз эченә түбәндәге мәгълүматларны туплый:

а) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең тиешле төренә кертелгән маршрутларда даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының номеры һәм исемен күрсәтеп;

б) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртүне планлаштыру;

в) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрутларын төзүне, үзгәртү һәм туктату;

г) Азнакай муниципаль районы бюджеты исәбеннән җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга муниципаль контракт төзелергә тиеш;

д) җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкару турында муниципаль контрактлар төзүне планлаштыру;

е) җайга салынмый торган тариф буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең бер яисә берничә маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык алу хокукына ачык конкурслар уздыруны планлаштыру;

ж) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары буенча халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка чараларны үткәрүне планлаштыру.

1.4. Планлаштыру документындагы белешмәләр Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында ачык һәм һәркем файдалана ала.

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда урнаштырылган муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документы мәгълүматларын яңарту Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының планлаштыру документына үзгәрешләр кертү турындагы тиешле норматив хокукый акты үз көченә кергән көннән алып 10 эш көне эчендә башкарыла.

**2. Планлаштыру документының структурасы һәм мәгълүматы**

2.1. Планлаштыру документы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеш бүлеге

тарафыннан, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар турында белешмәләр кертү юлы белән әлеге Тәртиптәге кушымта нигезендә алып барыла.

2.2. Планлаштыру документы дүрт бүлектән тора:

I бүлек - «Муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү төрләре»;

II бүлек - «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутларын үзгәртү планы»;

III бүлек - «Җайга салынмый торган тариф буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыклар бирү һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүнең җайга салынмый торган тарифы буенча даими рәвештә пассажирлар йортүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкару турында муниципаль контрактлар төзү план-графигы»;

IV бүлек - «Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка чараларны үткәрү планы».

2.3. Планлаштыру документының I бүлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәр муниципаль маршруты турында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) планлаштыру документында язуның тәртип номеры;

б) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының тәртип номеры (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестрыннан);

в) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестры нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршруты номеры һәм исеме;

г) планлаштыру документын раслау вакытына даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршруты өчен билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең факттагы төре (җайга салынмый торган тарифлар буенча);

д) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең тиешле муниципаль маршрутында (җайга салына торган тарифлар/җайга салынмый торган тарифлар буенча) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең планлаштырыла торган төре;

е) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең тиешле муниципаль маршрутында даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртү датасы (даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртү очрагында тутырыла, әлеге Тәртипнең 2 бүлегендәге 2.7 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килергә тиеш).

2.4. Планлаштыру документының II бүлегендә түбәндәге белешмәләр белән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары турында мәгълүмат булырга тиеш:

а) планлаштыру документында язуның тәртип номеры;

б) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының тәртип номеры (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестрыннан);

в) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестры нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршруты исеме;

г) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутын үзгәртү төре (билгеләү, үзгәртү яисә туктату);

д) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең гамәлдәге муниципаль маршруты яңа яисә үзгәртелгән очракта үзгәрешнең эчтәлеге (тутырыла);

е) үзгәреш датасы (әлеге Тәртипнең 2 бүлегендәге 2.7 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килергә тиеш).

2.5. Планлаштыру документының III бүлегендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары турында мәгълүмат булырга тиеш, алар буенча җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкару турында муниципаль контрактлар төзү буенча түбәндәге белешмәләр белән планлаштырылган чаралар каралган:

а) планлаштыру документында язуның тәртип номеры;

б) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының тәртип номеры (даими

рәвештә пассажирлар йөртүнең мунициапль маршрутлары реестрыннан) «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон) каралган булса;

в) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестры нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршруты исеме;

г)«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына торган тарифлар буенча муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкару турында муниципаль контракт төзү процедурасын уздыру көне (пассажирлар йөртүнең «җайга салына торган тарифлар буенча» төре билгеләнгән муниципаль маршрутларга карата тутырыла);

д) җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкару турында муниципаль контрактның гамәлдә булу датасы (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең «җайга салына торган тарифлар буенча» төре билгеләнгән муниципаль маршрутларына карата тутырыла);

е) конкурс процедураларын уздыруны Федераль закон нигезендә (конкурс үткәрү өчен Федераль законда каралган нигезләр булган очракта, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның «җайга салынмый торган тарифлар буенча» төре билгеләнгән муниципаль маршрутларына карата тутырыла);

ж) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булу датасы (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең «җайга салынмый торган тарифлар буенча» пассажирлар йөртүнең төре билгеләнгән муниципаль маршрутларына карата тутырыла).

2.6 Планлаштыру документының IV бүлегендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка чараларны үткәрү планлаштырылган, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары турында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) планлаштыру документында тәртип номеры;

б) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының тәртип номеры (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестрыннан);

в) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары реестры нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршруты исеме;

г) чараның исеме;

д) чараның эчтәлеге;

е) чараны уздыру датасы.

2.7. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең төрен үзгәртүгә, пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутларын туктатуга бәйле чаралар уздыру срогы һәм датасы Федераль закон нигезендә, пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы пассажирлар йөртүчеләрнең әлеге чаралар турында хәбәр итүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары үз көченә кергән көнгә кадәр йөз сиксән көннән дә соңга калмыйча һәм таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамлаганнан соң үз көченә керә.

Әлеге Тәртипнең 2 бүлегенең 2.3-2.6 пунктларында каралмаган белешмәләрне планлаштыру документына кертү рөхсәт ителми.

Азнакай муниципаль районында
Гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документын әзерләү тәртибенә кушымта
(формасы)

**______ елга Азнакай муниципаль районы гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне планлаштыру документы**

**1. Муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү төрләре**

| N п/п | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының номеры | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының исеме | Муниципаль маршрутта даими рәвештә пассажирлар йөртүнең факттагы төре | Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутының планлаштырылган төре | Даими рәвештә пассажирлар йөртү төренең үзгәрү датасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**2. Даими рәвештә пассажирлар йөртү муниципаль маршрутларын үзгәртү планы**

| N п/п | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының номеры | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының исеме | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутын үзгәртү төре (билгеләү, үзгәртү, туктату) | Үзгәртүнең эчтәлеге | Үзгәртү датасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**3. Җайга салынмый торган тариф буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга турында таныклыклар бирүгә бәйле эшләр башкару турында муниципаль контрактлар төзүнең план-графигы**

| N п/п | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының номеры | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының исеме | N 44-ФЗ Федераль законы нигезендә дәүләт контрактын төзү процедурасын үткәрә башлау | Муниципаль контрактның гамәлгә керү датасы | 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә конкурс процедурасын уздыра башлау датасы | Даими маршрут буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру буенча таныклыкның гамәлгә керү |
|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | датасы | | | датасы |
| | | | | | | |

## 4. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка чараларны үткәрү планы

| N п/п | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының номеры | Даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутының исеме | Чараның исеме | Чараның эчтәлеге | Чараның үтәлү срогы һәм вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |